КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 24 июль г.Казань № 881

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре» 2012 ел, 10 март, 202 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 13 октябрь, 852 нче; 2013 ел, 18 март, 176 нчы; 2013 ел, 31 октябрь, 829 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 257 нче; 2014 ел, 10 июль, 481 нче; 2015 ел, 21 гыйнвар, 25 нче; 2016 ел, 26 июль, 508 нче; 2016 ел, 19 август, 575 нче; 2017 ел, 10 ноябрь, 859 нчы; 2018 ел, 10 май, 340 нчы; 2019 ел, 3 апрель, 262 нче; 2019 ел, 16 июль, 588 нче; 2020 ел, 25 июнь, 525 нче; 2021 ел, 2 март, 110 нчы; 2021 ел, 6 декабрь, 1171 нче; 2022 ел, 30 декабрь, 1502 нче; 2023 ел, 17 март, 267 нче; 2023 ел, 9 июнь, 705 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсен тоту чыгымнарын тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан

Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча чикләрендә билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе турындагы нигезләмәдә:

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

3.3 пунктта:

3.3.17 пунктчада «ведомство» сүзеннән соң «максатчан» сүзен өстәргә;

3.3.40 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.40. Административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне гамәлгә ашыра.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.3.41 һәм 3.3.42 пунктчаларны өстәргә:

«3.3.41. Административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексы нигезендә Баш ветеринария идарәсе компетенциясенә кертелгән административ хокук бозулар турындагы эшләрне карап тикшерә.

3.3.42. Билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисенең һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары белән каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.»;

4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Баш ветеринария идарәсенең административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген билгеләргә.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.3 пункт өстәргә:

«4.3. Баш ветеринария идарәсе башлыгы, Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге буенча территориаль бүлекләр башлыклары Административ хокук бозулар турындагы Россия Федерациясе кодексының 8.52 статьясындагы 1 өлешендә, 2 өлешендә (үз вәкаләтләре чикләрендә) һәм 3 өлешендә, 8.54 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карап тикшерә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин